ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

Ш.Маннур ур., 72а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-44; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Карар
№ 38

Постановление
14.12. 2022 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге буенча Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 9 июнендәге № 39-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Олыяз авыл җирлеге Башкарма комитетының 2006 елның 21 декабрендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге буенча Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәне үз көчен югалтты дип танырга.
2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Житәкчесе И.Я.Хаев